Карар

Татарстан Республикасы Спас муниципаль берәмлегенең
Өчкүл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

11.10.2024 ел № 4

Спас муниципаль районының
Өчкүл авыл җирлегенең Үрнәк
торак пунктта гражданнардан
акчаларны кертү һәм алардан файдалану
2025 елда гражданнарның үзара салымы
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге башлыгы муниципаль районы

Карар кылды:

1. 2024 елның 31 октябрендә 11.00 сәгатьтә ТР, Спас районы Үрнәк ав., Вахитов ур., 26А йорт адресы буенча урнашкан Үрнәк авылы клубы бинасында, 2025 елда Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлегенең Үрнәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыены

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлегенең Үрнәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

«1) Үрнәк торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычлар һәм урамнарны яктырту лампаларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (эшләр өчен түләү) һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр));

2) Үрнәк торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урман урамы буенча авыл эчендәге юлны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү))».

“ ЯКЛАП”                    "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Өчкүл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Өчкүл авыл җирлеге башлыгы                                        Н.В. Емелюшина

СОВЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ